ГЛАВА ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 3-74-77; e-mail: Otar..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

“07”ноябрь 2019 ел. — № 5

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка» совхозы поселогы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, “Пятилетка” совхозы поселогы , Узэк урам , 3 нче йорт адресы буенча урнашкан “Пятилетка» совхозы поселогы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 20 ноябре, 16.00 сәгатьтэ Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка» совхозы поселогы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 1 нче кушымта нигезендә гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, “Пятилетка” совхозы поселогы, Централь урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан “Пятилетка” совхозы поселогы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 21 ноябре, 16.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка» совхозы поселогы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2 нче кушымта нигезендә гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга.

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенен “Пятилетка” совхозы поселогы торак пункты территориясендә

яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-“Пятилетка” совхозы поселогындагы суэтем башнясы коймасын урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-“Пятилетка” совхозы поселогындагы су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау (ремонт сетей водоснабжения) (материал, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- “Пятилетка” совхозы поселогы урамнары юлларын кардан чистарту;

« ӘЙЕ » « ЮК »

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетына “Пятилетка” совхозы поселогы торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

5. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге башлыгы: / Х.М.Минникаев/

Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге башлыгының
2019 елның 7 ноябрендә кабул ителгән карарына
1 нче кушымта

Бүленеш тәртибе (территориаль билге) буенча
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге
“Пятилетка” совхозы поселогы торак пунктында яшәүче гражданнар
жыенының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча беренче этабында катнашу
өчен исемлеге

| № п/п | Урам/ тыкрык атамалары | Йорт саннары |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан урамы | № 1-21 |
| 2. | Үзәк урам | №1-39 |

Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл
җирлеге башлыгының
2019 елның 7 ноябрендэ кабул ителгэн
карарына
2 нче кушымта

Бүленеш тәртибе (территориаль билге) буенча
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге
“Пятилетка” совхозы поселогы торак пунктында яшәүче гражданнар
жыенының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча икенче этабында катнашу өчен
исемлеге

| № п/п | Урам/тыкрык атамалары | Йорт саннары |
|---|---|---|
| 1. | Абз Дрсу урамы | №1 |
| 2. | Чулпан Кунакханэсе урамы | №1 |
| 3. | Бакча урамы | №1-48 |
| 4. | Ерганак урамы | №1 |